“Бу чын таяну ноктасы - “Акша келу” чәчәк атсын!” - Артём Здунов Зубово-Поляна районында яшәvчеләрне һәм кунакларны Изге Троица белән котлады.
Мордовия vзенен якты һәм vзенчәлекле милли бәйрәмнәре белән дан тота. Алар мордва халкына мәдәни традицияләрне һәм рухи кыйммәтләрне кvп гасырлар дәвамында сакларга, аларны киләчәк буыннарга тапшырырга ярдәм итә. Мордва халкынын кvркәм традициясе - Изге Троица православие бәйрәмендә халык кvнел ачулары vткәрv. Регионыбызнын кvп кенә авылларында бу конне чын кvнел ачу, ижат һәм халык осталары бәйрәме хокем сорә. Шундый мәйданчыкларнын берсе – “Ак каен” Республика милли-фольклор бәйрәме.

- Бу бәйрәм кvпмилләтле - биредә руслар, мордвалар һәм татарлар. Бvген безнен белән махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларнын гаилә әгъзалары, - дип сәламләде фестиваль кунакларын Мордовия Главасы Артём Здунов. - Борынгы бабаларыбыз бу конне очрашканнар, проблемалар, киләчәккә планнар турында фикер алышканнар. Бу чын таяну ноктасы!

Әйдәгез бу традицияне саклыйк! Без барыбыз да нык жеп белән бәйләнгән, шуна безне

сындырып булмый. Жинv безнен кулда булачак һәм “Акша Келу” чәчәк атсын.
Республика Главасы югары бvләкләр, шул исәптән мәдәният олкәсе хезмәткәрләренә, СВО катнашучыларына «Батырлык һәм кыюлык очен» билгеләре, шулай ук махсус операциядә катнашучыларнын туганнарына рәхмәт хатлары тапшырды.
Мордовия Дәvләт Жыены рәисе Владимир Чибиркин билгеләп vткәнчә, “Акша Келу” бәйрәме ярдәмендә мордва халкынын тарихы һәм традициял

әре саклана: “Мордовиянен игелекле, матур һәм эшчән халкынын бай тарихы бар. Бары тик бер-беребезгә ярдәм итеп, без теләсә нинди бурычларны - илебезне алгы сызыкта саклаучыларны һәм биредә vз хезмәте белән жинvне якынайтучыларны гына хәл итә алачакбыз. Без алга гына барабыз - республикабыз һәм боек Россиябез vсеше хакына”.
Рәсми олеш тәмамланганнан сон, Артём Здунов бәйрәм кунаклары белән аралашты, «Этнодеревни» павильоннарын карады - аларнын һәркайсы Мордовиядә яшәvче халыкларнын борынгы йолалары, традицияләре, матурлыгы һәм уникальлеге турында сойләде. Әйтеп китәргәкирәк, Мордовиянен татарлар яшәгән һәрбер районы мәдәниятыбызны лаеклы тәкъдим иттеләр. Чарада кvрше Темник районы “Митрялы” авыл клубы хезмәткәрләре милли татар гореф-гадәтләре, татар ое кvренешләрен чагылдырдылар: йон да эрләделәр, бишектә бәбине дә тирбәттеләр...
Павильоннарда декоратив-гамәли сәнгать осталарынын эшләре кvргәзмәсе, мастер-классlар, эшләнмәләр ярминкә-сату узды.
Гастрономия программасынын топ олеше милли кухня иде. Зубово-Поляна районы Горенка авылы татарлары мәдәнияты да кvрсәтелде. Анда авылда яратып пешерелә торган пәрәмәч, бәлешләр, алкалар, розалар яки кош телләре һәм тагы кvпторле ашамлыкларыбыз бар иде.